КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 июль г.Казань № 547

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен конкурс нигезендә бүлү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 7 июнь, 391 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен конкурс нигезендә бүлү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 7 июнь, 391 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 ел, 8 август, б-1123 нче боерыгы, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2010 ел, 3 декабрь, 552 нче приказы белән расланган Төбәк финанслары белән идарә итү сыйфатын бәяләүне һәм мониторинглауны гамәлгә ашыру тәртибе» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының кабул ителә торган чыгым йөкләмәләрен конкурс нигезендә бүлү тәртибенең 7 пунктындагы «ж» пунктчасында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин